КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 553

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан

Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче таблицаның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="2">«1.</td><td rowspan="2">«Республика физик культура һәм яшүсмерләр спорты үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесендә эшләү</td><td>педагогик хезмәт-кәрләр вазыйфа-лары</td><td>өченче</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>структур бүлекчә-ләр җитәкчеләре вазыйфалары</td><td>беренче</td><td>50,0»;</td></tr>
</table>

15 нче таблицаның «Республика физик культура һәм яшүсмерләр спорты үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе» юлында «20 000», «2 000» саннарын шул ук эзлеклелектә «30 000», «3 000» саннарына алыштырырга.

2. Бу карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин